ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

**2019 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының төп чаралар планын раслау турында**

Муниципаль районның гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын, көчләрен һәм чараларын әзерләү дәрәҗәсен алга таба күтәрү максатында,

КАРАР БИРӘМ :

1. Кушымталарны расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә 2019 елга төп чаралар планы (1 нче кушымта);

-2019 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарәсе органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен һәм район звеносын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләр (2 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районының гражданнар оборонасы хезмәтләре җитәкчеләренә, Югары Ослан муниципаль районының гражданнар оборонасы оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре җитәкчеләренә 2019 елда әлеге план үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

3. Югары Ослан муниципаль районының гражданнар оборонасы оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре җитәкчеләренә билгеләнгән

тәртиптә 2019 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чараларның тиешле планнарын эшләргә һәм гамәлгә кертергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Л. С. Хәкимҗановка йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы** **М.Г. Зиатдинов**